# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге составына керүче Тугыз торак пунктында (шул исәптән Келәүш урманчылыгы) 2021 елга үзара салым кертү турында

№ 1 | 09 ноябрь 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлегенең Тугыз торак пунктында (шул исәптән Келәүш урманчылыгы) узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Тугыз торак пунктында (шул исәптән Келәүш урманчылыгы) территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Тугыз торак пунктында Совет урамы ягына баручы юлны вак таш җәеп ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Тугыз торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

-Келәүш урманчылыгында Кооператив урамы ягына баручы юлны вак таш җәеп ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Келәүш урманчылыгында юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

3. Әлеге карарны Келәүш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Келәүш авыл җирлеге Башлыгы, Совет Б.В.Иванов